**ГЛАВА**
**МАСЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422647, с. Масловка,
ул. Центральная, дом 13

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МАСЛОВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ**
**БАШЛЫГЫ**

422647, Масловка авылы,
Центр урамы, 13 нче йорт,

Тел.: (84361) 253 55, факс: (84361) 253 55, e-mail: Masl.RS@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**22 ноябрь 2021 ел** Масловка ав. № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Масловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Масловка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2021 елның 03 декабрьдә 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Масловка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2021 елның 03 декабрьдә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Масловка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын 2021 елның 03 декабрьдә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Масловка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының дүртенче этабын 2021 елның 03 декабрьдә 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.
5. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
6. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Масловка авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Масловка авылының Центральный урамы буенча коймаларны ремонтлау;
- Масловка авылының 2 шт. күләмендә тирән насослар сатып алу һәм урнаштыру;
- Масловка авылы урамнарын һәм зират юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
- Масловка авылы урамнарын һәм зират юлларын төзекләндерү өчен вак таш ташу буенча транспорт хезмәтләре өчен түләү;
- Масловка авылы урамнарының юл йөрү өлешен кышкы чорда карап тоту (урамнарны чистарту);
- Заовражная урамы буенча елга аша күперне ремонтлау;
- Масловка авылы урамнарының читләрендә чүп үләннәре чабу һәм юлларны җәй көне карап тоту;
- Масловка авылы сууткәргечен ремонтлау.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Масловка авылы, Центральный урамы, 13 йорт, һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда кабул ителү белән 3 көн эчендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге
Башлыгы А.И.Егоров